СОВЕТ
СИЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д. 1, с.Смак-Корса,
Арский муниципальный район, 422025

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СЕЖЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Мәктәп урамы, 1 йорт, Курса Почмак авылы,
Арча муниципаль районы, 422025

Тел. (84366)93-1-24, факс (84366)93-1-24. E-mail: Smk.Ars@tatar.ru

# КАРАР

**« 19 » октябрь 2017 ел** **№ 2**

**Төзекләндерү кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Сеҗе авыл җирлеге Уставы, Сеҗе авыл җирлегендә, Сеҗе авыл җирлеге Советының 2009 елның 19 октябрендәге 53 номерлы карары белән (2012 елның 06 февралендәге 12 номерлы үзгәрешләр белән) расланган Сеҗе авыл җирлегендә халык хокукларын муниципаль хокукый актлар проектлары буенча фикер алышуда катнашу өчен гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә карар бирәм:

1.Сеҗе авыл җирлеге Советының 2012 елның 29 декабрендәге 32 номерлы карары белән расланган Сеҗе авыл җирлегенең Җир куллану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында карар проекты буенча гавами тыңлауларын 07.11.2017 елга билгеләргә.

2. Гавами тыңлауларны Сеҗе авыл җирлеге Советының «Сеҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында карар проекты буенча 10.00 сәгатьтә ТР, Арча муниципаль районы, Курса Почмак авылы, Мәктәп урамы, 1адресы буенчаүткәрергә.

3. Сеҗе авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләренә тәкъдим ителә торган үзгәрешләр буенча гражданнарның тәкъдимнәре, искәрмәләре һәм гавами тыңлауларда катнашуга гаризалары язмача рәвештә 16 сәгатькә кадәр җибәрелә дип билгеләргә. 07.11.2017 елга кадәр түбәндәге адрес буенча җибәрергә: ТР, Арча муниципаль районы, Курса Почмак авылы, Мәктәп ур., 1 й., тел.88436653236

4. Әлеге карарны һәм Сеҗе авыл җирлеге Советының «Сеҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында карары проектын Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru), Арча муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Сеҗе авыл җирлеге башлыгы Гибадуллина Г.М.